КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 март г.Казань № 203

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның хәлен яхшырту буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2003 ел, 16 май, 266 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның хәлен яхшырту буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2003 ел, 16 май, 266 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 27 август, 515 нче; 2004 ел, 15 гыйнвар, 5 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 818 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1119 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:»;

икенче абзацта «акыл» сүзен «интеллектуаль» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларын, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрне (алга таба – ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен

махсуслаштырылган учреждениеләр) азык-төлек продуктлары, өс киеме, аяк киеме, дару чаралары, йомшак инвентарь һәм кирәкле җиһаз белән тәэмин итәргә;»;

алтынчы абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларында, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә булган, тәрбияләнгән һәм белем алган ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен түбәндәгеләрне билгеләргә:»;

өченче абзацта «учреждениеләрдә» сүзен «оешмаларда» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр, әлеге оешмаларның (учреждениеләрнең) попечительләр советлары белән килештереп, ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга аларның шәхси чыгымнары өчен әлеге оешмаларның (учреждениеләрнең) тиешле максатларга каралган акча чикләрендә акча түләү күләмнәрен билгели.»;

3 пунктта «учреждениеләрдә» сүзен «оешмаларда» сүзенә алмаштырырга, «һәм гаилә тибындагы балалар йортларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта:

икенче абзацта «барлык типтагы укыту-тәрбияләү учреждениеләрен, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрне» сүзләрен «ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларын, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрне» сүзләренә алмаштырырга, «кимендә 200 сум күләмендә» сүзләрен «кимендә 100 сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар (урта һөнәри белем бирелә торган мәгариф программаларын һәм югары белем бирелә торган мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт белем бирү оешмаларында көндезге формада укуын дәвам итүче затлардан тыш) бу карарның 5 нче кушымтасы нигезендә өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз белән, шулай ук кимендә 2 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие белән тәэмин ителә;»;

бишенче абзацта «укыту-тәрбияләү учреждениеләре һәм уку йортларын» сүзләрен «әлеге белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе Саклык банкы учреждениесендәге чыгарылыш укучы исеменә;» сүзләрен «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә Россия Федерациясе банкында чыгарылыш укучысы исеменә ачылган счетка» сүзләренә алмаштырырга;»;

алтынчы абзацта «производствода эшләргә өйрәтүгә» сүзләрен «уку» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктта «республика шәһәрләре һәм районнары администрацияләре башлыкларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы шәһәр округларының, муниципаль

районнарының җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга, тиешле сандагы һәм килештәге «учреждение» сүзен тиешле сандагы һәм килештәге «оешма» сүзенә алмаштырырга;

7 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 яшьтән һәм аннан олырак ятим балалар оешмаларындагы тәрбия бирү төркемнәрендә иң чик кеше саны булу – төркемдә иң күбе 8 кеше, ә 4 яшькә кадәрге төркемнәрдә – иң күбе 6 кеше;»;

8 пунктта «балалар йортларына һәм интернат мәктәпләргә» сүзләрен «оешмаларга» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бала йортларындагы төркемнәрдә иң чик кеше санын түбәндәгеләрдән исәпләп:

5 кеше – туганнан алып 1 яшькә кадәр,

6 кеше – 1 яшьтән 4 яшькә кадәр;

дәүләт сәламәтлек саклау системасы һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ кимендә 20 бала булганда, социаль хезмәткәр ставкасын бирү.»;

12 пунктта «республика шәһәрләре һәм районнары администрацияләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Татарстан Республикасы шәһәр округларының, муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1 һәм 12 пунктларына таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.»;

әлеге карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 5 нче кушымтада:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларында, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларында һәм теләсә нинди ведомство карамагындагы башка белем бирү оешмаларында булган ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга алар эшкә урнашканда бирелә торган өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһазлар исемлеге»;

искәрмәләрдә:

1 пунктта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «уку йортларына» сүзләрен «белем бирү оешмаларына» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин